РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 февраль 2021 ел № 04

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Башкарма комитетының 2018 елның 23 нче гыйнварындагы 02 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәреш кертү турында (2020 елның 20 гыйнварындагы 01 нче номерлы, 2020 елның 10 апрелендәге 12 нче номерлы карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын фаразланган үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсенең 24,25 пунктларын үтәү йөзеннән, карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Башкарма комитетының 2018 елның 23 нче гыйнварындагы 02 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (2020 елның 20 гыйнварындагы 01 нче номерлы, 2020 елның 10 апрелендәге 12 нче номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 5 пунктны түбәндәге эчтәлекле өченче абзац белән тулыландырырга:

«Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар алу шарты булып Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү буенча бурыч (үтәлмәгән бурыч) булмау тора.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http//pravo.tatarstan.ru. веб – адресы буенча урнаштыру юлы белән һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.И. Солтанов